РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**исполнительный комитет**
**Большесалтыковского сельского поселения**

422831, Республика Татарстан,
Камско-Устьинский район,
с. Б.Салтыки, ул.Х.Такташ, 132
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**

422831, Татарстан Республикасы,
Кама Тамагы районы,
Олы Салтык авылы, .Х.Такташ урамы, 132
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.01.2020** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы “2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында " карарларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән башлап җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6124,86 сум дип билегләргә һәм 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 нчы елның 24 апрелендәге 24 номерлы

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында”карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Салтык авылы, Свердлов ур., 126;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 шулай ук хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемдә калдырам.

Җитәкче Х. Х. Ибәтов

1 кушымта
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
30.01 2020 №1

2020 елның 1 февраленнән башлап Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә бәяләр

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3670,18 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 522,27 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмүгә) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

2 кушымта
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
30.01 2020 №1

2020 елның 1 февраленнән башлап Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә бәяләр

| **Хезмэт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 188,35 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3481,83 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 522,27 |
| 4.Җирләү (кабер казу һәм күмүгә) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |